وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

**Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!**

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№8 (177). 22 февраль 2013 / 12-рабыгыль-ахир-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ




23 февраль – Ватанны саклаучылар көне

▷ 2,4 ◁



Г.Исхакый һәм Г.Тукай әсәрләрендә гаилә тәрбиясе проблемалары

▷ 3 ◁



*Зәй мөхтәсибе:* "Эшлим дигән кешегә мөмкинлекләр туып кына тора"

▷ 4 ◁

## ИР-АТ — САКЛАУЧЫ

**Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) болай дигән: "Сез барыгыз да көтүчеләр һәм сез барыгыз да үзегезнең көтүегез өчен җаваплы (кемнәр өчен җавап бирергә тиешсез, шулар өчен җаваплы)". Бу хәдис ир-атлар турында һәм алар өчен әйтелгән. Чөнки Аллаһы Тәгалә хатын-кызларга гаилә учагын саклау, балалар тәрбияләү, ирләренең күңелләрен күрү сәләтен, ә ир-атларга гаиләләрен яклау өчен көч-куәт биргән.**



Нәкъ менә шуңа күрә, һәр сәламәт ир-атка җаваплылык хисе хас. Мөселман кешесе үзе турында гына уйлый алмый. Беренчедән, никах - иманның яртысы, ә бу Аллаһы Тәгалә һәм җәмәгатьчелек каршында - зур җаваплылык. Моннан тыш, ир-атларда физик көчләрен куллану ихтыяҗы бар. Бу бары тик ир-атның гына гаилә һәм ил сакчысы була алуы турында сөйли. Әлеге табигый ихтыяҗ соңгы вакытта кими башлады. Җәмгыятьтә ир балалар өчен куркыныч агымнар барлыкка килде: унисекска (җәмгыятьтә ир-ат һәм хатын-кызларның тоткан урыннары үзгәрү; төп билгесе: ир-атлар һәм хатын-кызлар киемендәге тәңгәллек) иярү, гадәти булмаган җенси ориентацияләрне пропагандалау, гаилә институтының абруе киму, җенси тотнаксызлык һәм идеология системасының таркау булуы.

Ислам - сәламәт җәмгыять нигезе. Бу диннең кыйммәтләре ир балага кызларга охшау теләген булдырмый. Мөселман үзен иҗтимагый алгарышның этәргече буларак хис итеп, үзенең тырышлыгы һәм берөзлексез көрәше нәтиҗәсендә нәселе, халкы һәм иле тагын да көчлерәк булуына инанып тәрбияләнә. Бу - дөньякүләм диннәрнең барысының да идеологиясе. Без моны нигезләп, алдагы буыннарга да җиткерергә тиеш.

Мөселман ир-аты көчле кеше, яхшы гаилә башлыгы, тәрбияле һәм кайгыртучан ул, чын дус һәм эшендә намуслы хезмәткәр булырга тиеш. Болар барысы да җаваплылык хисе булганда гына мөмкин. Ә җаваплылык - Аллаһы Тәгалә алдындагы бурычыбыз. Ул безгә чын ир-ат булу өчен бөтен мөмкинлекләрне дә биргән. Бу - без барыбыз да омтылырга тиешле идеал. Бу - рәсүлебез Мөхәммәд (сгв) үрнәге.

"Ий мөэминнәр! Һәммәгез дә берләшкән хәлегездә Коръән эчендә булган тынычлык, хаклык юлына керегез! Әмма Коръән хөкемнәренә, тынычлык юлына каршы булган шайтан юлына кермәгез! Ул сезгә мәгълүм булган ачык дошман". ("Бәкара (Сыер)" сүрәсенең 228 нче аяте).

Ир-атларда җаваплылык дәрәҗәсе, һәрчак, безгә Аллаһы Тәгалә бүләк иткән физик көчебез һәм хисси куәтебез сәбәпле, күбрәк булачак. Шуңа да рәхмәтле һәм җаваплы булыйк.

***Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ***

## Чаңгы ярышына рәхим итегез!

**Көчле һәм сәламәт мөселман гаиләсе... Өммәтебез бу турыда һәрвакыт кайгыртырга тиеш. Шул максатны күздә тотып, 23 февраль - Ватанны саклаучылар көнендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте чираттагы спорт чарасы - чаңгы ярышы уздырачак.**



Ярышны үткәрү өчен мөфтиятнең "Алтын урта" мөселман яшьләре җәмгыяте җаваплы. Россиянең физик тәрбия һәм спорт отличнигы Рафаэль Мифтахов хәбәр иткәнчә, әлеге ярышта ир-атлар гына түгел, хатын-кызлар, балалар да катнаша алачак. Ярыш күп кенә мөселман гаиләләрен бергә җыяр, дип көтелә. Барлык теләүчеләр өчен - балалар һәм өлкәннәр арасында да эстафета уздыру каралган. Моннан тыш, "Алтын урта" җәмгыяте төрледән-төрле күңел ачу программалары, спорт уеннары, конкурслар үткәрәчәк. Чаңгы ярышында, уеннарда җиңүчеләргә кыйммәтле бүләкләр - интернет-планшет, электрон китап, флешка, MP3-плеер тапшырылачак.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең яшьләр белән эшләү бүлеге җитәкчесе Акйолдыз Фәйзова хәбәр иткәнчә, "Лыжня Ислама" дип аталган әлеге спорт чарасы сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, физик культура һәм спортны популярлаштыру, мөселман яшьләрен кышкы спорт төрләренә җәлеп итү максатыннан оештырыла. Шунысын да искәртеп үтик: катнашучыларга хәмер куллану һәм провокацион лозунглар белән чыгу тыела.

Чаңгы ярышы "Хезмәт резервлары" стадионында иртәнге сәгать унда (10.00) башланачак. Чаңгыларны нибары 80 сум түләп арендага алу мөмкинлеге тудырылачак. "Хезмәт резервлары" стадионы М.Горький исемендәге паркка керү юлында урнашкан. Аның адресы: Казан шәһәре, Николай Ершов урамы, 7а йорт.

**Белешмәләр өчен телефон: +7 (843) 238-17-61 (Диния нәзарәте).**

## ЯҢАЛЫКЛАР

### "ХӘЛӘЛ" КОМИТЕТЫ - "EURO-ASIA EXPO 2013" ХАЛЫКАРА КҮРГӘЗМӘСЕНЕҢ РӘСМИ ПАРТНЕРЫ

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтененең "Хәләл" стандартлар комитеты "EURO-ASIA EXPO 2013" Халыкара күргәзмәсенең рәсми партнеры булды.** Әлеге бөек Ефәк юлы традицияләрен торгызу максатыннан оештырыла торган күргәзмә 3-6 октябрь көннәрендә Казанда үткәреләчәк.

"EURO-ASIA EXPO 2013" кысаларында "KAZANHALAL 2013" күргәзмә-ярминкәсе дә уздырыла. Быел хәләл ризык җитештерүчеләрне бергә җыя торган чараның төп темасы - "Гаилә кыйммәтләре һәм традицияләр".

Күп кенә Европа һәм Азия илләре "EURO-ASIA EXPO 2013" Халыкара күргәзмәсендә катнашырга теләк белдерде инде. Алар арасында Бөекбритания, Германия, Дания, Франция, Болгария, Кытай, Һиндстан, Япония, Сингапур һәм башка илләр бар.

### ДИНИ ҺӨНӘРИ МӨСЕЛМАН БЕЛЕМЕ БИРҮЧЕ УЧРЕЖДЕНИЕЛӘРНЕҢ УКУ-УКЫТУ-МЕТОДИК БЕРЛӘШМӘСЕ БУЕНЧА ЭШ ТӨРКЕМЕ УТЫРЫШЫ ҮТКӘРЕЛДЕ

**18 февраль көнне Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дини һөнәри мөселман белеме бирүче учреждениеләренең уку-укыту-методик берләшмәсен оештыру буенча эш төркеменең утырышы үткәрелде.**

Эш төркеменә мөфти вазифаларын башкаручы Габдулла хәзрәт Әдһәмов, ТР Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаментының дини берләшмәләр белән багланышлар идарәсе җитәкчесе Илнур Гатауллин, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы рәисе Рөстәм хәзрәт Батыров, Ислам тикшерүләр үзәге өлкән фәнни хезмәткәре Камил Насыйбуллов, Татарстан мөфтиятенең мәгариф һәм фән бүлеге мөдире Айдар хәзрәт Карибуллин, методист Нәзирә Гыйззәтуллина, "Мөхәммәдия" мәдрәсәсенең укыту эшләре буенча проректоры Зөлфәт хәзрәт Габдуллин, РИУның укыту эшләре буенча проректоры Марат хәзрәт Гыйльманов керде.

Утырышта сүз методик берләшмәнең нигезнамәсен кабул итү турында барды. Эш төркеме әгъзалары эшләнә торган документка төзәтмәләр кертте, тәкъдимнәрен җиткерде. Әлеге орган дини мөселман уку йортларына универсаль мәгариф стандартлары, программалар әзерләү, аларны гамәлгә ашыру һәм шулай ук фәнни-методик ярдәм күрсәтү белән шөгыльләнәчәк.

**Чыганак: www.dumrt.ru**

### МӨНӘҖӘТЛӘР БӘЙГЕСЕНӘ КӨТЕП КАЛАБЫЗ!

**Бөгелмә шәһәре һәм районы мөхтәсибәте җирле Татар мәдәнияте үзәге белән берлектә "Зәйтүнә" мөнәҗәтләр конкурсы уздырырга карар кылды.** Әлеге ярыш бәйгесен беренче генә мәртәбә уздырсак та, Татар мәдәнияте үзәге каршында эшләп килүче "Мирас" ансамбле чыгышларын тыңлаучылар моны күптән тәкъдим итеп килә иде. Менә тәвәккәлләдек. Мондый моңлы тавышлы әби-апаларыбыз төбәгебездә шактый лабаса. Укучы яшьләребез арасында да үзләрен сәхнәдә күрсәткән тәүфикълы, иманлы туташларыбыз аз түгел. Әле үз сәләтләрен сәхнәгә чыгып күрсәтергә кыенсынып торучылар барлыгын да беләбез. Шуңа күрә мөнәҗәтләрне яраткан, үзләре дә башкарырга атлыгып торган өммәттәшләребезне 24 февраль көнне үткәреләчәк чарада көтеп калабыз! Конкурсның шартларын +7 (85594) 4-16-98 телефонына шалтыратып белешә аласыз. Электрон адресыбыз - rustam83@rambler.ru.

23 ФЕВРАЛЬ – ВАТАННЫ САКЛАУЧЫЛАР КӨНЕ

# Халык педагогикасында һәм ислам тәгълиматында ватанпәрвәрлек, батырлык, каһарманлык идеяләре



**Татар халкы - кешелек тарихында тирән эз калдырган милләт. Аның бай тарихы, күп гасырлар буена тупланган кыйммәтле матди һәм рухи мәдәнияте, асыл гореф-гадәтләре, традицияләре, күпкырлы педагогикасы бар. Борын-борыннан ук халкыбызның тәрбия тәҗрибәсендә һәм исламда Ватан, халык, ил-җиргә бирелгәнлек, батырлык игътибар үзәгендә булган. Әлеге сыйфатлар кешенең иҗтимагый һәм социаль җитлегүенең бер дәлиле буларак, аеруча әһәмиятле. Бу уңайдан шушы төшенчәләрнең асылын ачыклау халкыбыз тарихында аларның тоткан урынын тасвирлауны күпкә җиңеләйтер һәм аңлаешлы итәр.**



Ватан ул - кешенең туган җире; халыкның тарихи үсеш үзенчәлекләре, теле, мәдәнияте, көнкүреше, гореф-гадәтләре һәм традицияләре белән бергә яши торган җире, аның табигате. "Ватан - кеше үзе туган һәм шуның гражданины булган ил; туган ил; кешенең туган ягы, туган җире" ("Татар теленең атлатмалы сүзлеге"ннән).

Патриот һәм ватанпәрвәрлек (патриотизм) төшенчәләренең асылына төшенү өчен дә аңлатмалы сүзлеккә мөрәҗәгать итү урынлы булыр: "Патриот - үзенең туган җирен, халкын, илен, Ватанын сөюче, шулар өчен һәртөрле корбаннарга да әзер булган кеше. Ватанпәрвәрлек - патриотларга хас булган күренеш (эш, теләк, хис); үз иленә, халкына мәхәббәт".

Шулай итеп, ватанпәрвәрлек - үз иленә, халкына, туган теленә, табигатькә, милли традицияләргә, мәдәнияткә олы мәхәббәт ул. Тик ул еш кына бик авыр, катлаулы каршылыкларны һәм кыенлыкларны, психологик кичерешләрне җиңү белән бәйле. Бу хис "батырлык" төшенчәсе белән аваздаш. Батырлык максатка бирелгәнлекне, аны тормышка ашыруда ныклык күрсәтүне аңлата. Ул үз-үзеңне тота алу, каушап калмау, чыдамлылык, файдалы эшләргә әзер булу, бурычны үтәү кебек сыйфатларны үз эченә ала. Башка халыклардагы кебек үк, татар халкына да хас гүзәл сыйфатлар байтак. Шуларның берсе - батырлык, каһарманлык, Ватанны саклауда һәм хезмәттә үз-үзеңне аямау, фидакарьлек. Чөнки халкыбыз баһадир халык булып оешкан. Батырлык - милләтебезнең горурланырлык сыйфаты. Халкыбыз беркайчан да Ватанына хыянәт итмәгән; татарларны куркаклыкта, батырлыклары җитмәүдә гаепләү адымына берәүнең дә базганы юк әле. Күренекле шагыйрь Хәсән Туфан халкыбызга борынгыдан хас әлеге сыйфатны "сокландыргыч" дип атап, аны "И татар" дип аталган шигырендә болай тасвирлый:

*Синең дә, и татар*
*Сыйфатың, саның бар.*
*Холкыңда, йолаңда*
*Сокланзыч ягың бар.*
*Синең төп сыйфатың -*
*Батырлык, кыюлык.*
*Синең бу гадәтең*
*Байрагың булырлык!*

Халкыбызның бөек шагыйре Г.Тукай исә татар халкының борынгыдан килгән әлеге гүзәл сыйфатларын үзенең "Олуг юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре" дип аталган шигырендә аеруча образлы итеп тасвирлый алган:

*... Без сугышта*
*юлбарыстан көчлебез,*
*Без тынычта аттан*
*артык эшлибез...*

Моның белән шагыйрь үзенең тарихи, иҗтимагый-социаль проблемаларны тирән аңлавын дәлилли. Ватанның бәйсезлеген саклауда халкыбызның юлбарыстан көчле булуын дәлилләгән мисалларны күпләп китерергә булыр иде. Шундыйларның берсе итеп Кол Шәрифнең үз шәкертләре белән берлектә Ватанны саклауда батырларча һәлак булуларыннан алып, халкыбызның Бөек Ватан сугышында фашизмга каршы аяусыз көрәштә ил-җир бәйсезлеге өчен күрсәткән каһарманлыгы һәркемне сокландыра һәм киләчәк буыннарга үрнәк булып тора. Әлеге дәһшәтле бәрелештә ил буенча 11500 сугышчы Советлар Союзы Герое исеменә лаек булса, татарларда бу сан ике йөздән артып китә. Моңа өстәп, җиде миллион кешенең орден-медальләр белән бүләкләнүен дә әйтеп үтәргә кирәк. Бу саннар халкыбызның Ватан өчен көрәштә чыннан да "юлбарыстан көчле" булуын дәлилли. Шулай итеп, дошманнарда була алмый торган иң көчле коралыбыз - туган илгә булган чиксез мәхәббәт һәм массакүләм батырлык бөек җиңүнең тантана итүенә китерде. Бу дәһшәтле сугышта фронтта да, тылда да халыкның күрсәткән ватанпәрвәрлеге, массакүләм батырлыгы турында хәзер төрле караш-фикерләр бар. Ничек кенә булмасын, ул чорда халыкның ватанпәрвәрлегә эчкерсез, аяусыз һәм көчле булган. Чөнки ул ил-җир, Ватан өчен көрәшкән һәм эшләгән. Халыкта бик көчле патриотлык, ватанга бирелгәнлек хисе тәрбияләнгән. Шуңа күрә көчле ватанпәрвәрлек хисе, халыкка олы мәхәббәт - әлегә кадәр күрелмәгән шул дәһшәтле, аяусыз бәрелештә җиңеп чыгуыбызның төп сәбәпләреннән берсе, дип әйтергә була. Ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү уңаеннан, боларга өстәп, шул чорның тагын бер үзенчәлеге турында фикер йөртү кирәктер. Бөек Ватан сугышында әле атеистик пропаганданың бөтен асылын тоярга-үзләштерергә өлгермәгән күп кенә өлкән буын кешеләренә дә катнашырга туры килде. Алар исламда тасвирланганча, ата-баба җиренең никадәр олы сәгадәт булуын аңлап, үлем белән йөзгә-йөз очрашканнар, күпләп ятып калганнар, аяусыз көрәштә дошманга бирешмичә, җиңүгә ирешкәннәр. Димәк, җиңүнең сәбәбен тагын шуның белән аңлатырга мөмкин: халкыбыз Ватанның үз гаиләсеннән, үз туган туфрагыннан, ата-бабалары яткан изге җирдән башлануын, ирек һәм азатлык алу өчен кешедә ватанпәрвәрлек хисенең өстенлек алырга тиешлеген аңлаган. Кыскасы, аларда туган җиренә, газиз туфрагына ихтирам, аның мәнфәгатьләре өчен барча кыенлыкларга түзәргә әзер булу хисе көчле булган. Бу бик тә табигый. Чөнки өлкән буын, исламдагы рухи кыйммәтләр белән беррәттән, халкыбызда тупланган тәрбия тәҗрибәсенең асыл мәгънәсен үзләштереп, үзенең гамәл-адымнарын шундагы тәгъбирләр белән үлчәгән, аларны яшәешнең нигезе итеп таныган. Менә аларның кайберләре: "Батыр булсаң - йөрәктән, көчле булсаң - беләктән", "Батырдан үлем дә курка", "Батырга каян да юл такыр", "Батыр даны ил теләндә", "Куркак үләр - уе гел үлемдә. Ант үләр - ияре калыр, адәм даны калыр".

Бөек Ватан сугышында халкыбызның юлбарыстан көчле булып, илбасарларга каршы бердәм булып күтәрелүе, ил-җир хакына тылда көнне төнгә ялгап аттан артык эшләве, ачялангачлыкны җиңеп, газап-михнәтләр аша массакүләм батырлык, чыдамлык, аяусызлык күрсәтүе җиңүне якынайта. Бу уңайдан бик күп мисаллар китерергә булыр иде. Әлеге вазгыять илебез халыклары әдәбиятында һәм фәнни хезмәтләрдә киң яктыртыла. Шундый хезмәтләрнең берсе - Ш.Мәрҗани ис. Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Тәэминә Биктимированың "Ил язмышын салып иңнәренә" китабы. Анда халкыбызның сугыштагы һәм тылдагы каһарманлыгы дәлилле, образлы итеп тасвирлана.

Кыскасы, патриотик тәрбиянең, ватанпәрвәрлекнең асыл мәгънәсен тасвирлап, мәшһүр җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Садри Максуди болай дип яза: "Бөтен милләтләр үзләренең барлыкка килүләрендә һәм мөстәкыйль мөһим роль уйнаган ил-йортка (Ватанга) мөкатдәс бер нәрсә итеп карыйлар. Бөтен милләтләр Ватанга бәйле милли берәмлекне бер изге нәрсә буларак кабул итәләр. Ватаныңны сөю - милли хиснең, милләтчелекнең мөһим бер өлешедер. Үзеңнең ил-йортыңны олылау вә хөрмәтләү милли халык формалашуда да зур роль уйный". Монда тасвирланган сыйфатларның кешедә тәрбияләнүе - аның Ватанга хезмәт итәргә, аны сакларга әзер булуының иң кирәкле алшарты булып тора. Бу проблемалар ислам тәгълиматында да бик калку яктыртыла. Шуңа күрә уку йортларында патриотик тәрбиянең башка алымнары белән бергә, исламдагы кыйммәтләрне дә тулы файдаланып, комплекслы эш алып бару мөһим бурыч булып тора. Бу урында әлеге өйрәтүләрнең асыл мәгънәсен ачыклау урынлы булыр.

Ватанны дошман һөҗүменнән саклау, халыкның иреген һәм тынычлыгын тәэмин итү өчен дәүләт төзегән гаскәрдә хезмәт итү һәр ватандашыбызның вазифасыдыр. Бу вазифа ислам диненең әмередер. Димәк, гаскәрдә хезмәт итүдән баш тартуны дини ышануларына нигез итеп алучыларның аклануын динебез кире кага. Төрле сылтаулар табып, хәрби хезмәткә бармау яки барганнан соң качып кайту - ханилыктыр, түбәнлектер, гөнаһтыр, диелә шәригатьтә. Ватанның бәйсезлеген саклау, халыкның азат һәм тыныч яшәвен тәэмин итү өчен армиядә хезмәт итү, тәвәккәллек һәм батырлык күрсәтү - һәр ир кешенең вазифасы. Бу җәһәттән Коръәни-Кәримдә максат ачык бәян ителә: "Мөэминнәр безнең гаскәрләребездер, алар, әлбәттә, дошманнарын җиңәрләр". (Биредә "Саффат (Сафта торучылар)" сүрәсенең 173 нче аяте Ногмани тәфсире буенча бирелә.) Чыннан да, халык әйтмешли, "Ил йомышы - олы йомыш". Чөнки монда сүз илнең мөстәкыйльлеген, халыкның азатлыгын, үз кануннары буенча яшәргә хокукын саклау һәм яклау турында бара. Шуңа күрә халкыбыздагы "Ватан өчен җан фида" дигән тәгъбир бик борынгыдан килә.

(Ахыры 4 нче биттә.)

# Г.ИСХАКЫЙ һәм Г.ТУКАЙ

## әсәрләрендә гаилә тәрбиясе проблемалары

**Әлеге мәкаләдә татар халкының классик язучылары - Г.Исхакый һәм Г.Тукай әсәрләре мисалында әхлак тәрбиясе бирү үзенчәлекләре карала. Быел Г.Исхакыйның тууына - 135, Г.Тукайның вафатына 100 ел тула. Халкыбызның бөек уллары иҗатына күзәтүне шул уңай белән тәкъдим итәбез.**





Мәшһүр проза остасы Гаяз Исхакый һәм бөек шагыйрь Габдулла Тукай - татар әдәбияты күгенең иң якты йолдызлары. Замандашлар буларак, алар үз чорларында ук бер-берсенең иҗатларын бик югары бәяләгәннәр. Тукай яшь чагында ук Исхакыйның әсәрләрен яратып укыган, тора-бара бу әсәрләргә мәхәббәте тагын да арткан һәм, ахыр чиктә, әдипнең үзен дә идеаллаштыра башлаган. 1906 елда язылып, 1907 елда дөнья күргән "Кем ул?" исемле шигырендә ул, мәсәлән, Г. Исхакыйны милләтне күтәргән шәхес итеп карый. Шигырьдә мондый юллар бар: "Кем ул бу милләте тәрфигъ идән (үстергән) кәс?"; "Караңгыда идек, аттырды таң" (ягъни "Таң йолдызы" газетасын чыгара башлады). "Узган көннәребез турында уйлаткан кем?"; "Безгә инкыйразны аңлаткан кем?"

Габдулла Тукайның Гаяз Исхакыйга багышланган "Мөхәрриргә" шигырендә дә әдип "Ул Гомәрдән курка шайтаннар" дигән төсле рәсүл; Бер карашың иң шома ялганчыны сүздән тыя..." - дип мактала. Билгеле булганча, Гомәр бине Хаттаб - пәйгамбәребез Мөхәммәд Саллә-ллаһу галәйһи вә сәләмнең сәхабәсе. Ул туры сүзле, кыю, көчле, гадел кеше булган. Барлык мөшрикләр дә аңардан бик нык курыкканнар. Нәкъ менә Гомәр ислам динен кабул иткәч кенә, мөселманнар ачыктан-ачык дәгъват кыла алганнар. Пәйгамбәребез (сгв) аны "Фарук", ягъни хаклыкны ялганнан аеручы, дип атый. Моннан күренгәнчә, Тукай Исхакыйны Гомәр белән тиңләп, аның гаделлеген, туры сүзле булуын, бернидән дә курыкмавын югары бәяли.

Гаяз Исхакый, үз чиратында, Г.Тукайга карата шулай ук гаять уңай мөнәсәбәттә булган. 1913 елда Петербургта Тукай кичәсе үткәрергә рөхсәт бирмәгән хөкүмәт органнарына протест йөзеннән язылган, "Ил" газетасында басылып чыккан мәкаләсендә аның шундый сүзләре бар: "Тукай бар иде, Тукай бар. Һәр үткән көн, һәр мәдәни атлаган адым Тукайны зур итәчәк, үстерәчәк кенәдер. Тукайның исеменә ябыштырылган һәр мәгънәсез хәрәкәт Тукайны халык йөрәгенең кадерлесеннән-кадерле урынга гына утыртачак, Тукайның әдәби, мәдәни хезмәтендә тоткан урынын һичбер төрле какшатмаячактыр. Тукай яши, Тукай яшәячәк. Татар милләте яшәгәнгә кадәре Тукай яшәячәк".

"Тукай - мәктәптә", "Милли фаҗига", "Мәрхүм Тукай" исемле мәкаләләрендә дә Исхакый Тукайга бик югары бәя бирә, аның әсәрләренең бөтен татар халкы өчен җан азыгы булуын дәлилли.

Гаяз Исхакый да, Габдулла Тукай да, милләтнең үз балалары буларак, милләт бәхете, азатлыгы өчен үзләренең үткен кораллары белән көрәшәләр. Милләтне инкыйраз авырыуннан саклап калу максатында, аның игътибарын халыкның милли яшәешенә, күркәм гореф-гадәтләренә, милли йолаларына, нәселнәсәбенә, борынгы тамырларына юнәлтәләр. Әлеге мәкаләбездә сүз бу ике талант иясенең татар-мөселман көнкүрешен, гаилә тормышын, гаиләдә бала тәрбияләү күренешләрен чагылдырган әсәрләре турында барачак.

Гаяз Исхакый - зур реалист, ул татар тормышындагы күренешләрне бөтен нечкәлекләре белән сурәтләгән. Аның әсәрләре чын мәгънәсендә татар дөньясының энциклопедиясе булып тора. "Татарлар, - ди Гаяз Исхакый, - борынгы заманнан бирле уңган, акыллы, укымышлы халык, киң күңелле һәм максатка омтылучан горур табигатьле милләт. Ул, дөньяның башка халыклары кебек үк, тигез хокуклы булып дөньяга килгән һәм шул принциплар нигезендә яшәргә тиеш. Моның өчен, әлбәттә, фикердә, уйда һәм гамәлдә хөрриятькә ирешергә кирәк". "Моңа ирешү өчен нишләргә кирәк соң?" - дигән сорауга язучы җавапны борынгы тамырларыбыздан, гореф-гадәтләребездән, ислам диненнән, төрки кардәшләребездән һәм тарихи хәтеребездән эзләргә чакыра.

Гаяз Исхакый әсәрләрендә гаилә тормышын, гаиләдә бала тәрбиясен сурәтләүгә аеруча зур игътибар бирелә. Аның беренче әдәби әсәре - "Тәгаллемдә сәгадәт" (1897) урта хәлле крестьян гаиләсендә туган авыл малаеның шәһәр мәдрәсәсендә укырга теләве һәм укуы, тырышып укып, мәдрәсәне тәмамлаганнан соң, яхшы гаиләдән чыккан тәрбияле Казан кызына өйләнеп, матур гаилә корып җибәрүе һәм бәхетле тормыш коруы турында. Әсәрдә "белем алу мөселманнар өчен фарыз" дигән фикер уздырыла. Гаиләдә, тормышта бәхетле булыр өчен, аң-белемле булуның, тәпле тәрбия алуның зарурилыгы күрсәтелә.

Әдипнең "Бай углы" (1903) исемле әсәрендә шулай ук гаилә тәрбиясе проблемасы күтәрелгән. "Тәгаллемдә сәгадәт" хикәясендә аң-белемле ата-ананың тәпле тәрбиясе балага уңай тәэсир иткәнлеге сурәтләнсә, "Бай углы"нда исә, киресенчә, Фатыйх бай белән хатыны Сәгыйдә бердәнбер уллары Кәримне аздыруга, һәлакәткә китерүгә төп сәбәпче булалар. Гәрчә, улларының азуында алар аның яшь хатыны - саф күңелле унҗиде яшьлек Бәдрияне гаеплиләр: "Кәримнең исраф итүе ата-анасыны ахырында йортларыннан чыгарырга сәбәп булса да, Сәгыйдә бикә берлән Фатыйх бай, аның бу кадәр начарлануына сәбәп - Бәдрия генә, дип беләләр иде. Дөресте генә, бу эшләргә сәбәп: Фатыйх байның дөнья рәтен белмәве, Сәгыйдә бикәнең бала тәрбиясендә хәбәрсезлеге, Сәхилә әбинең юк-бар сүзләренә ышанып, аның сүзе берлә баласыны мәктәптән алулары, Фәхри кеби мәктәп бусагасына аяк басмаган, китап битенә күз ташламаган, дин белмәгән, дөнья күрмәгән жулик малайга иптәш итеп, аның берлән йөрүләре иде". Әсәрдә үзләрен "чын мөселман" дип күрсәтүче, әчынлыкта мәҗүсилек белән шөгыльләнүче имче-томчы, багучы карчыклар, надан остазлар фаш ителә. Алдынгы карашлы, җәдитчелек методы белән укытучы галимнәр һәм укучылар - авторның идеалы.

Язучы бала тәрбияләүдә ананың иң зур роль уйнавын ассызыклый: бала тәрбияли белми торган, надан Сәгыйдә улының матди яктан тәэмин ителүе белән канәгать, ә килене Бәдрия үз улы Рәфгатькә рухи тәрбия бирә, яхшы мәктәптә укыта. Рәфгать акыллы, белемле, тәрбияле, иманлы бала булып үсә. Җан тынычлыгын ул Коръән укуда таба, әбисенең дә, барлык хаталарын аңлап, иманга килүенә сәбәпче була.

Гаилә тормышының төрле якларын сурәтләргә омтылып, Гаяз Ихакый Финляндиядә яшәгән чорда "Фамилия сәгадәте" ("Гаилә бәхете") исемле хикәяләр циклын тудыра һәм аны 1912 елда аерым китап итеп бастыра. Циклга "Татар гакылы", "Мәдрәсә җимеше", "Башкорт бәхете" һәм "Көтелгән бикәч" хикәяләре керә. Бу әсәрләрдә төп игътибар бәхетле гаилә коруга киртә булган мәсьәләләргә юнәлгән. "Татар гакылы" хикәясендә ата-ананың, яшьләрдән акыллырак булып күренергә теләп, гаилә коруда аларның теләкләрен, хокукларын санга сукмавының аянычлы хәлләргә китерүе күрсәтелә. "Башкорт бәхете" һәм "Көтелгән бикәч" хикәяләрендә яшьләрне алдан бер-берсен күрми һәм белми өйләндерү гадәтенең аянычлы нәтиҗә китерүе турында сөйләнә. Гаяз Исхакыйның "Алдым-бирдем" драмасында да яшьләрнең бәхетле гаилә коруларына аяк чалучы кадими карашлы, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы икәннәре фаш ителә. "Фамилия сәгадәте" циклы хикәяләрендәге геройлардан аермалы буларак, "Алдым-бирдем" пьесасының төп героинясы - Галия (Хәлил бай Шакиров белән Гарифә бикә кызы) үзләренә туган тиешле Ибраһим Шакировны ярата. Аңа, беренче булып, хат аша ачыктан-ачык мәхәббәтен белдерә, үз бәхете өчен үзе көрәшә. Кызның әнисен һәм туганы Әхмәдине аның бәхетле килечәге кызыксындырмый, бәлки аны бай кешегә биргәннән соң килә торган мал, байлык кызыксындыра. Тик Галия белән Ибраһим, пардан рөхсәт сорап тормыйча гына "алдым-бирдем" ясыйлар, ягъни шаһитлар күзәтеп торганда ярәшәләр. Ата-аналар, шәригать хөкемнәрен бозып, яшьләрнең никахлашуына катгый каршы килгән очракта, яшьләр алар рөхсәтеннән башка да өйләнешергә хаклы. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: ислам динендә хатынкызның беренче булып мәхәббәт белдерүе, ячуы җибәрүе - рөхсәт ителгән гамәл. Пәйгамбәребезнең (сгв) беренче хатыны Хәдичәнең дә, үзе беренче булып, Мөхәммәдкә кияүгә чыгарга теләп, ячуы җибәргәне мәгълүм.

Татарлар арасында ата-ананың үз кызларын көчләп кияүгә бирүләре яки яшьләрнең бер-берсен алдан күрмичә өйләнешүләре кебек хәлләр еш булган. Тик ислам диненең моңа кискен каршы булуына да дәлилләр күп. "Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм өйләнергә җыенучы бер ирдән: "Булачак хатынның күрдеңме?" - дип сорый. Тегесе: "Юк", - дигәч, кыз янына барып, аны күрергә куша". Түбәндәге хәдис тә игътибарга лаек: "Элек кияүдә булган хатын-кыз, аның үзе белән киңәшүдән башка, кияүгә бирелми. Саф кыз да, үз ризалыгын белдермәгән килеш, кияүгә бирелми". Димәк, яшьләр бер-берсен күреп, ошатып, үз ризалыкларын белдереп, ата-ана рөхсәтен алып һәм шаһитлар алдында никахлашырга тиеш. Шул чакта гына бәхетле, ныклы гаилә хасил була ала. Күп кенә кешеләрнең шәригатьне белмәве яки белергә теләмәве аркасында яшь егет-кызларның күбесе аянычлы язмышка дучар була. Гаяз Исхакый искәрткәнчә, бу бәхетсезлекләрнең сәбәбе ислам динендә түгел, бәлки ислам диненең төп асылын белергә теләмәүдә.

*(Дәвамы киләсе санда.)*



Зәй мөхтәсибе:

# "Эшлим дигән кешегә мөмкинлекләр туып кына тора"

*Тулы исеме:*
**Сәгыйть хәзрәт КАМАЛОВ.**
***Туган көне һәм туган урыны:*** 1936 елның 27 мае, хәзерге Теләче районы.
**2002 елның сентябреннән Зәй районы имам-мөхтәсибе булып эшли.**

***- Мөхтәсиб булып эшли башлавыгызга да дистә елдан артык вакыт узып киткән. Республикабыздагы аксакал хәзрәтләребезнең берсе буларак, хезмәт тәҗрибәгез белән уртаклашсагыз иде.***

- Төп юнәлешләребезнең берсе - яшьләр белән эшләү. Мөхтәсиб булып сайланган беренче елларымда ук балалар өчен лагерьлар оештыруны максат итеп куйдык. (Балаларыбызны баштарак Түбән Камага йөртә идек.) Балалар белән эшләү өчен билгеле бер белемкүнекмәләргә ия булу таләп ителә. Шуңа күрә имамнарыбызны башта Чаллыдагы Ак мәчеттә укыттык, узган елны хәзрәтләребез Казанга - Имамнарның белемен арттыру үзәгендә дә булып кайтты. Мөхтәсибәтебездәге дин әһелләре тыгыз элемтәдә яши. Аена ике мәртәбә - һәр айның беренче һәм өченче чәршәмбесендә мөхтәсибәт җыелышларын үткәрәбез. Эшләү дәверендә балалар өчен лагерьлар оештыру буенча зур тәҗрибә туплый алдык.

***- Шул тәҗрибәгез турында газета укучыларыбызга да сөйләп китә алмассызмы?***

- Лагерьлар якшәмбе мәктәпләреннән үсеп чыкты. Җәй саен ике смена оештырабыз, смена саен утызлап бала ял итә. Балаларны лагерьга җыйганда берданбер таләп булып, аларның яше - 10-15 яшьтә булулары тора. Безгә бу яшьтәгеләр белән эшләү җиңелрәк.

***- Быел рамазан ае җәй уртасына туры килә, лагерьлар үткәрүдә кыенлыклар булмасмы?***

- Алла боерса, булмас. Башка елларны балалар лагерьда кунып ял итә иде. Узган елдан балаларны кундырмый башладык, чөнки алар өчен төнгә каравылчы кую, иминлекне кайгырту мәслихәт, дигән нәтиҗәгә килдек. (Беребез дә хәвеф-хәтәрдән имин түгел бит.) Шулай булса да балаларны көненә биш тапкыр ашаудан өзгәнебез юк. Смена дәвамында кая да булса сәфәр оештырабыз: Г.Тукайның Арча районындагы музейларына да барганыбыз булды. Лагерьлар түләүле түгел, балаларны кабул итү өчен бары тик ата-ананың гаризасы гына кирәк. Узган елның рамазан аенда мәчетебездә сәхәр ашауны да оештыра алдык: хәтта сәхәргә килүче балалар да булды. Шуны да әйтеп үтәсем килә: мондый лагерьларның нәтиҗәлелеге якшәмбе мәктәпләренә караганда күпкә артык.

***- Шулай да бүгенге көндә сезне ниләр борчый, хәл ителмәгән нинди проблемалар бар?***

- Хәзерге вакытта безне иң нык борчыган мәсьәлә - белгечләр (белемле кадрлар) җитешмәү. Мисал өчен, районыбыздагы 32 мәхәлләнең сигезендә генә дипломлы имамнар хезмәт куя. Ә бит мәчет эше дини мәрасимнәрне үтәүгә генә кайтып калмый, дәүләт оешмалары белән дә эшли белү сорала. Кызганыч ки, дөньяви да, дини дә белеме булган имамнарга кытлык кичерәбез. Яшьләребез эшкә килгәч ныгып кала алмый.

Аллага шөкер, эшлим дигән кешегә мөмкинлекләр туып кына тора. Берничә ел элек районыбыздагы бер мәктәп оптимальләштерү язмышына дучар булган иде. Үз эшчәнлегебезне алып бару өчен ярап куяр дип, шул мәктәп бинасын мөхтәсибәт исеменә күчерү артыннан йөрибез. Ул бик матур урында урнашкан, аңа ремонт булганга да күп вакыт түгел әле. Барысы да без теләгәнчә килеп чыкса, балалар өчен лагерьларны каникул саен үткәрә алачакбыз. Мөхтәсибәтебезгә өч гектар җир дә бүлеп бирелде. Аны да нәтиҗәле файдалану юлларын эзлибез.

***- 2012 елның 1 сентябреннән илебезнең барлык мәктәпләрендә дә IV-V сыйныф укучыларына "Россия халыкларының рухи-әхлакый мәдәнияте нигезләре" (элегрәк ул "Дини мәдәният нигезләре һәм дөньяви этика" дип атала иде) дигән яңа фән кертелде. Сез бу яңалыкны ничек кабул иттегез?***

- Безнең өчен иң кулай юл - һәр авылда якшәмбе мәктәпләре оештыру. Без мәктәпкә керә алмыйбыз. Анда укыту, тәрбия эше алып бару өчен педагогик осталык кирәк. Имамнар мәктәпкә укытырга йөри башласа, күңелемне шик биләп ала, нәрсәдер килеп чыкмас кебек. Ә бит дин әһелләре алдында торган төп бурыч - мәчетләрдә якшәмбе укуларын җайга салу. Быел исә дини дәресләргә башлангыч сыйныф укучыларын - көндез, ә урта сыйныф балаларын куна торган итеп оештырылган лагерьларга җыярга, дип торабыз.

***- Безнең җирлек өчен чит-ят булган төрле агымнарга каршы торуда ниләр тәкъдим итәр идегез?***

Районыбыздагы дин әһелләрен борчыган иң зур мәсьәлә - Зәй шәһәрендә "Йәһвә шаһитләре (Свидетели Иеговы)" хәрәкәтенең киң колач җәюе. Аның башлыгы Санкт-Петербургта укып кайткан. Әлеге секта вәкилләре кешенең психикасы белән уйный: "Дөнья беткәч без генә калабыз" дип, алар халыкны үзләре артыннан ияртмәкче булалар - эзләнүчән яшьләрне, матур итеп сөйләп, үзләренең кармагына эләктерә баралар. Мондый секта юлын 2-3 ай таптаган кешене аннан тиз генә аерып та алып булмый. Чөнки аларның башлыгы әллә нинди буш вәгъдәләр биреп, кешене үзен белештерә алмаслык хәлгә җиткерә. Шуңа күрә хәзрәтләребездән гел уяу булу сорала. Баштарак алар безнең мәчетләребезгә дә килгәләп, халыкның башын бутап йөргән иде. Дин кардәшләребезгә, мөхтәсибләргә әйтәсе килгән сүзем шул: мөхтәсибәттә дәгъват эше яхшы итеп оештырылырга тиеш. Мондый агымнарга бергәләшеп көрәшкәндә генә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешә алырбыз, дип уйлыйм.

**Нияз САБИРҖАНОВ**
**әңгәмәсе**

## Кадерле дуслар!



**22 яшьлек, шат күңелле яшь кыз сезнең ярдәмегезгә мохтаҗ. Таныш булыгыз - Миләүшә Газизова. Ул Актаныштa яши, тыйнак елмаюы белән генә дә тирә-яктагыларны үзенә карата.**

**Миләүшәдә Саркома Юинга авыруы (сөяк миендә яман шеш) тапканнар. Дәвалануның беренче этабы Казанда үтә, ләкин нәтиҗәсез була. Шеш үскәннән-үсә. Хәзер Миләүшәгә чит ил белгечләре генә ярдәм итә ала. Дәвалану якынча 4 миллион сумга төшәчәк. Ул дәвалана торган клиника счёты белән сез Миләүшәнең рәсми төркемендә таныша аласыз: http://vk.com/club48622834.**

**Дүрт миллион сум Россия кешесе өчен зур сумма. Ләкин кешеләргә һәрвакыт кызгану һәм шәфкатьлелек хисе хас. Исәпләп карагыз: 20 мең кеше 200 сум бирсә Миләүшә сәламәтләнә алачак.**

**Кеше хәленә керә алу һәм шәфкатьлелек безне Аллаһы Тәгаләгә якынайта, бу сыйфатлар бездә булмаса, бездә бернәрсә дә юк дияргә була (Иоанн Златоуст).**

**Миләүшә өчен ярдәм кулын сузуы авыр түгел. Сез үзегезгә җайлы теләсә нинди юл белән акча күчерә аласыз (барлык реквизитлар да ВКонтакте сайтындагы төркемдә бирелгән).**

**Сәламәт һәм бәхетле булыгыз!**

**Татфондбанк карточкасы номеры - 4172270007077285**
**Телефон номеры - Билайн: 89093121925**
**Киви кошелёк - +79600608171**
**ЯНДЕКС КОШЕЛЕК - 410011450592629**

## Халык педагогикасында һәм ислам тәгълиматында ватанпәрвәрлек, батырлык, каһарманлык идеяләре

***(Ахыры. Башы 2 нче биттә.)***

Куркаклык, сугыш кырыннан качып китү, халыкка, Ватанга хыянәт иң хурлыклы, түбән дәрәҗәдәге гамәлләр буларак, дин тарафыннан кискен гаепләнә. Бу уңайдан, халык педагогикасындагы тәгъбир-риваятьләр бик гыйбрәтле: "Куркактан җир җирәнгән", "Куркак аулакта батыр була" һ. б. Милләтнең батыр уллары, каһарманнарның фидакарьлеге халык, милләт хәтерендә мәңге саклана. Моңа бәйле рәвештә Садри Максудиның фикерләве бик мәгънәле. Ул болай дип яза: "Җир йөзендәге барлык милләтләр кыю һәм батыр затлар, бөек шәхесләр тудыралар. Милләтнең хәятендә, тәрәккыяте өчен көрәшләрдә фидакарьлек күрсәткән, Ватанга гадәттән тыш хезмәтләре белән дан алган кешеләргә каһарман исеме бирелер. Мондый бөек шәхесләр милләтнең хәтерендә онытылмас эз калдыралар. Үз милләтен сөйгән шагыйрьләр бу каһарманнар истәлегенә мәдхияләр вә җырлар иҗат иткән, алар хакында дастаннар язган. Шул рәвешчә каһарман үз милләтенең хәтер хәзинәсендә күренекле урын алган". Күргәнебезчә, галим фикерләре бу өлкәдә исламдагы кыйммәтләр белән дә аваздаш. Ислам тәгълиматында һәм халык педагогикасында да гаделлек өчен, Ватан, халык мәнфәгатьләрен яклап, көрәштә батырлык күрсәткән инсаннар мактала, бердәмлекнең зур көч булуы ассызыклана. Ил-җирен, Ватанын, халкын саклаучы мөселман кешесе куркыныч килгән вакытларда югалып калмас, һәр эштә бөтен кодрәтен кулланыр һәм дә Аллаһы Тәгаләгә генә таяныр. Ватанга, ата-бабалар җиренә хыянәт иткән кеше, бер яктан, халык нәфрәтенә дучар булса, икенче яктан, дөньяда да, ахирәттә дә җәзасын алачак. Мондый гамәл Коръәндә болайрак тасвирлана: "Ул чагында, һичшиксез, Без сиңа тормышның һәм үлемнең әчесен кат-кат татыткан булыр идек. Ул чагында син үзеңне Миннән яклар өчен дус табалмас идең". (Биредә "Исра (Төнге йөрү, Ягъкуб угыллары)" сүрәсенең 75 нче аяте Батулла тәрҗемәсендәгечә бирелә.) Әлеге аятьнең асыл мәгънәсен халкыбыз тәгъбирләре дә куәтли: "Ил кадерен белмәгән - башын югалтыр, җир кадерен белмәгән ашын югалтыр", "Көтүен ташлаган малны бүре алыр, илен ташлаган ирне гүр алыр" һ. б. Динебез өйрәткәнчә, дәүләт, халык йөкләгән бурыч зур тырышлык, тәвәккәллек, нык ихтыяр көче белән җиренә җиткереп башкарылырга тиеш.

Йомгак ясап әйткәндә, дәүләтебез һәм җәмгыятебез үсешенең хәзерге этабында, әдәп-әхлак тәрбиясе белән беррәттән, яшьләрдә ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү, Ватан, ил-җир, ата-баба йорты, алар яшәгән изге җир төшенчәләренең асыл мәгънәсен аңлату, шулар нигезендә яшәргә өйрәтү, гадел гамәлләр кылып, акыл белән тормыш итәргә күнектерү - җәмгыятьнең дә, мәгариф системасының да өстенлекле бурычы булып тора. Гаскәрнең рухи һәм физик сәламәтлегеннән илнең бөтенлеге, халыкның иртәгәсе көнгә өметле, ышанычлы булуы тора. Бу гаять катлаулы бурычны хәл итүнең иң зарури шартларыннан берсе итеп тәрбия эшендә халык педагогикасындагы һәм исламдагы бик тәэсирле һәм үтемле рухи-әхлакый кыйммәтләрне бөтен тулылыгы белән файдалану - нәтиҗәлелекнең төп гарантиясе. Әлеге кыйммәтләрне бүгенге чынбарлык белән бәйләп, аларга нигезле аңлатмалар бирү лазем. Бу эш системалы булганда гына яшьләребезнең гамәлләре тотрыклы булачак.

**Ильяс ХАЛИКОВ,**
**Россия ислам институтының табигый-гуманитар фәннәр кафедрасы мөгаллиме**

## МӘДРӘСӘ КИТАПХАНӘСЕН БЕРГӘЛӘП БАЕТЫЙК!

Буа мәдрәсәсе 1805 елда ачылган һәм ул республикабыздагы тарихи мөселман уку йортларының берсе. Биредә булачак дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре, фән һәм мәдәният хезмәткәрләре белем алган. Әйтик, Зариф Бәшири, Шакир Мөхәммәдов, Һади Атласи, Камәретдин Салихов, Гомәр Толымбай, Бакый Халидов, Габдрахман Таһирҗанов, Ибраһим һәм Касыйм Биккуловлар, Фатыйх Мортазин, Гарифҗан Вәлидов (Буави) исемнәре генә дә ни тора! Шулай итеп, Буа мәдрәсәсе 1919 елга кадәр эшләгән. 1997 елда мәдрәсәбез үз ишекләрен янә ачты.

Озак еллардан бирле мәдрәсәнең үз китапханәсен баету юнәлешендә эш алып бару өчен матди ягыбыз мөмкинлек бирмәде. Быел китап киштәләре күбәйтелде, хәзер исә китапханәне яңарту һәм фондны тулыландыру эше алып барыла.

Рухи байлыгыбызны киләчәк буыннарга җиткерүдә үз өлешләрен кертергә теләүчеләр мәдрәсә китапханәсенә үзләренең ярдәм кулын суза ала.

Хәзер күпләрнең өендә динебез кыйммәтләрен, милли-рухи мирасыбызны пропагандалаган, күренекле дин әһелләренә, гомумән, дин гыйлеменә багышланган китаплар шактый. Мәдрәсә китапханәсен баетырга теләүчеләрнең дини китапларны түбәндәге адреслар буенча тапшыруын сорыйбыз:



**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте (Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 йорт. Тел.: +7 (843) 238-35-18);**

**Буа мәдрәсәсе (Буа шәһәре, К.Либкнехт урамы, 79 йорт. Тел.: +7 (84374) 3-70-71, факс: 3-73-96. Кесә телефоны: +79276735357, электрон почта адресы: islambuinsk@mail.ru).**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 8 (177) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** № 35391.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция һәм нәшер итүче адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27. "Дин вә мәгыйшәт" газетасы редакциясе. Язылу индексы - 16046.
***График буенча бу санга 21 февраль көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклаеыгыз!**